**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 30 сентябрь | № 696

г. Казань

Татарстан Республикасы идарә итә һәм эш итә торган җир кишәрлекләрен шәһәр округлары территорияләрендә даими яшәүче өч яки күберәк баласы булган гражданнарга биргәндә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары арасында үзара багланышлар тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32[1] статьясындагы 5, 19[1] пунктлар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы идарә итә һәм эш итә торган җир кишәрлекләрен шәһәр округлары территорияләрендә даими яшәүче өч яки күберәк баласы булган гражданнарга биргәндә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары арасында үзара багланышлар тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасы шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы белән үзара багланышларын гамәлгә ашырганда Тәртип нигезендә эш итәргә тәкъдим итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы — А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\696.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 30 октябрь, 696 нчы
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы идарә итә һәм эш итә торган җир кишәрлекләрен шәһәр округлары территорияләрендә даими яшәүче өч яки күбәрәк баласы булган гражданнарга биргәндә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары арасында үзара багланышлар тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^{1}$ статьясындагы 5, $19^{1}$ пунктларны тормышка ашыру максатларында эшләнде һәм Татарстан Республикасы идарә итә һәм эш итә торган җир кишәрлекләрен шәһәр округлары территорияләрендә даими яшәүче өч яки күбәрәк баласы булган гражданнарга биргәндә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы (алга таба – Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы) һәм Татарстан Республикасы шәһәр округларының җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) арасында үзара багланышлар механизмын билгели.

## 2. Үзара багланышларда катнашучыларның төп бурычлары һәм функцияләре

2.1. Үзара багланышларны гамәлгә ашыру максатында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы җирле үзидарә органнары белән җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм эш итү мәсьәләләре буенча үзара багланышлар турында тиешле килешү төзи.

2.2. Үзара багланышлар үз эченә Татарстан Республикасы шәһәр округлары территорияләрендә даими яшәүче өч яки күбәрәк баласы булган гражданнарга (алга таба – күп балалы гаиләләр) Татарстан Республикасы идарә итә һәм эш итә торган җир кишәрлекләреннән барлыкка килгән җир кишәрлекләрен (алга таба – җир кишәрлекләре, җир кишәрлеге) бирү мәсьәләләре буенча мәгълүмат алмашу һәм чаралар үткәрүне оештыруны үз эченә ала. Үзара багланышлар даими нигездә гамәлгә ашырыла.

2.3. Җирле үзидарә органы белән үзара багланышлар кысаларында (килешү буенча) түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

Татарстан Республикасы идарә итә һәм эш итә торган җир кишәрлекләреннән файдалану максатларын саклап, җир кишәрлекләре барлыкка китерү;

күп балалы гаиләләргә бирү өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре исемлеген формалаштыру;

һәр гариза бирүчегә уникаль исәп номеры биреп, җир кишәрлеге алуга хокуклары булган гражданнар исемлеген формалаштыру һәм алып бару;

җир кишәрлеге алуга хокуклары булган гражданнар исемлегенә кертү яисә кертүдән баш тарту турында карар кабул итү;

законнар нигезендә җир кишәрлеген сайлау актын рәсмиләштереп, җир кишәрлеген сайлау процедурасын үткәрү;

тәкъдим ителә торган җир кишәрлекләре карталарында сайланган җир кишәрлекләрен билгеләү һәм алга таба тиешле мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштыру;

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32[1] статьясындагы 9 пункт нигезендә җир кишәрлеге алуга гариза биргән күп балалы гаиләләр буенча документлар архивын алып бару;

җир кишәрлекләре алуга гаризалар реестрын, Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 өлештә күрсәтелгән нигезләр буенча милеккә җир кишәрлекләре бирелгән (тапшырылган) гражданнар реестрын алып баруны тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт министрлыгының күп балалы гаиләгә җир кишәрлеге бирү турында карарлары (алга таба – җир кишәрлеге бирү турында карар) проектларын һәм җир кишәрлеген бирү-алу актлар проектларын әзерләү;

бирелгән җир кишәрлекләренә хокук күчүне рәсмиләштерүне тәэмин итү;

күп балалы гаиләгә җир кишәрлекләре бирү мониторингы.

2.4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт министрлыгы белән үзара багланышлар кысаларында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

җирле үзидарә органнарына консультация, оештыру һәм методик ярдәм;

әлеге Тәртипнең 3.2 пунктында каралган документларны карап тикшерү, җир кишәрлеген бирү турында карарлар кабул итү һәм җир кишәрлеген бирү-алу актлар проектларын имзалау.

2.5. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт министрлыгы күп балалы гаиләгә җир кишәрлекләре бирү белән бәйле документларны җирле үзидарә органыннан соратып алырга хокуклы.

## 3. Җир кишәрлеге бирү турында карар кабул итү буенча үзара багланышлар тәртибе

3.1. Җир кишәрлеге бирү турында карар формасын Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы раслый.

3.2. Җирле үзидарә органы (килешү буенча) күп балалы гаилә һәм җирле үзидарә органы җир кишәрлеген сайлау актын имзалаган көннән соң дүрт эш көне эчендә җир кишәрлеген бирү турында карар проектларын, күп балалы гаилә имзалаган җир кишәрлеген бирү-алу актын әзерләүне һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан җир кишәрлеген бирү турында карар кабул итү өчен, Татарстан Республикасы Җир кодексының

32[1] статьясындагы 10 пунктта каралган документлар күчермәләрен теркәп, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына җибәрә.

3.3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы әлеге Тәртипнең 3.2 пунктында күрсәтелгән документларны (алга таба – документлар комплектын) алган көннән соң 10 эш көне эчендә документлар комплектын карап тикшерә һәм түбәндәге гамәлләрнең берсен башкара:

а) җир кишәрлеген бирү турында карар кабул итә һәм документлар комплектын җирле үзидарә органына юллый;

б) җирле үзидарә органы документларның тулы комплектын тапшырмаган яисә документлар комплектын карап тикшергәндә кимчелекләр билгеле булган очракта җирле үзидарә органы кимчелекләрне бетерсен өчен документлар комплектын кире кайтара. Бу очракта җирле үзидарә органы (килешү буенча) документлар комплектын алганнан соң биш эш көне эчендә билгеле булган кимчелекләрне төзәтә һәм аны кабат Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Җир кодексының 32[1] статьясындагы 14[1] пунктта билгеләнгән вакытларны исәпкә алып, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы җир кишәрлеген бирү турында карар кабул итү өчен җибәрә.

3.4. Әлеге Тәртипнең 3.3 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә документлар комплектын кабат җибәргәннән соң Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы документлар комплектын карап тикшерә һәм әлеге Тәртипнең 3.3 пунктында каралган гамәлләрнең берсен башкара.

3.5. Әлеге Тәртипнең 3.3 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә җир кишәрлеген бирү турында карар кабул ителгән һәм бирү-алу акты имзаланганнан соң Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы җир кишәрлеген бирү турында карарны, җир кишәрлеген бирү-алу актын һәм документлар комплектын җирле үзидарә органына җибәрә.

---